ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СӘЛӘНГЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАР

№ 19 28 май 2021 ел

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Сәләнгеш выл җирлеге Советының керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында һәм цифрлы финанс активлары һәм цифрлы хокуклар турында белешмәләр тапшыру хакында

Россия Федерациясе Президентының «Цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары турында» 2020 елның 10 декабрендәге 778 номерлы Указын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Сәләнгеш авыл җирлеге советы КАРАР ИТТЕ:

1. 2021 елның 30 июненә кадәр (бу көнне дә кертеп) «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Сәләнгеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүгә дәгъва итүче гражданнар, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Сәләнгеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче гражданнар, муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Сәләнгеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлегенә кертелгән вазыйфаларны биләгәндә гражданнар керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм аларны биләгәндә, шулай ук Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Сәләнгеш авыл җирлеге Советының 2014 елның 5 ноябрендәге 133 номерлы карары белән расланган хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, муниципаль учреждениеләр җитәкчеләренең Вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль учреждениеләр җитәкчеләренең вазыйфаларын биләүче гражданнар, «Россия Федерациясе Президентының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмә формасын раслау һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 23 июнендәге 460 номерлы Указы белән расланган белешмә формасы буенча тапшырыла торган белешмәләр белән бергә, «Цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары турында» Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 10 декабрендәге 778 номерлы Указына

1 нче кушымта нигезендә «Цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары турында» Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 10 декабрендәге 778 номерлы Указына 1 нче кушымта нигезендә алар, аларның ире (хатыны) һәм балигъ булмаган балаларының булган цифрлы финанс активлары һәм башка цифрлы хокуклар, утилитар цифрлы хокуклар һәм цифрлы валюта (алар булганда) турында хәбәрнамә тапшыра.

2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Сәләнгеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Сәләнгеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Сәләнгеш авыл җирлеге Советының 2016 елның 19 апрелендәге 25 номерлы карары белән расланган белешмәләр тапшыруы турында нигезләмәгә, 8 пунктның «3» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«3) җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, пайлар), хисап чорында цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) сатып алуга кагылышлы алыш-биреш буенча үз чыгымнары, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белешмәләр, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы алыш-биреш башкарылганга кадәрге соңгы өч елда әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) гомуми кеременнән артып китсә һәм алыш-биреш башкарылган акчаларны алу чыганаклары хакында.».

3. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Сәләнгеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва итүче гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Сәләнгеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Сәләнгеш авыл җирлеге Советының 2014 елның 5 ноябрендәге 133 номерлы карары белән расланган нигезләмәгә 6 пунктның «в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп үзгәрешләр кертергә:

«в) җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, цифрлы финанс активлары, хисап чорында цифрлы валюта (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) сатып алуга кагылышлы һәр алыш-биреш буенча үз чыгымнары, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белешмәләр, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы алыш-биреш башкарылганга кадәрге соңгы өч елда әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) гомуми кеременнән артып китсә һәм алыш-биреш башкарылган акчаларны алу чыганаклары хакында.».

4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга, шулай ук Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Сәләнгеш авыл җирлеге
Советы Рәисе А.Н. Пинин